ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**19.02.2025**

**К А Р А Р**
**№ 223**

**2025 елга гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бясенең максималь күләмен билгеләү турында**

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Төзелеш министрлыгының «Россия Федерациясе буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метры һәм Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясенең бәясен билгеләү методикасын раслау турында» 2024 елның 28 мартындагы 215/пр номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Социаль наем шартнамәсе буенча торак урын мәйданының исәпкә алу нормасы һәм торак урын мәйданын бирү нормасы турында» 2021 елның 20 апрелендәге 75 номерлы карары нигезендә, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елга гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясе күләмнәренең түбәндәге максималь кыйммәтләрен билгеләргә:

1.1. Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган кереме күләменең максималь кыйммәте, исәп-хисап нигезендә (1 нче кушымта) тәшкил итә: гаиләнең һәр әгъзасына 32236,00 сум.

1.2. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең максималь күләме:

1.1.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен – 1284048,00 сум;

1.1.2. Ике кешедән торган гаилә өчен –2568096,00 сум;

1.1.3. Өч кешедән торган гаилә өчен – 3852144,00 сум;

1.1.4. Дүрт кешедән торган гаилә өчен – 5136192,00 сум;

1.1.5. Биш кешедән торган гаилә өчен –6420240,00 сум;

1.1.6. Алты кешедән торган гаилә өчен – 7704288,00 сум;

1.1.7. Җиде кешедән торган гаилә өчен – 8988336,00 сум;

1.1.8. Сигез кешедән торган гаилә өчен – 10272384,00 сум;

1.1.9. Тугыз кешедән торган гаилә өчен – 11556432,00 сум;

1.1.10. Ун кешедән торган гаилә өчен – 12840480,00 сум.

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырып игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының торакны исәпкә алу һәм бүлү бүлеге башлыгы Л.Н. Шумковага йөкләргә.

Җитәкче Р.Ф.Хәкимуллин

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитетының
19.02.2025 223
номерлы карарына кушымта

**2025 елга гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең максималь күләмен билгеләү**

**МЕТОДИКАСЫ.**

1. Наем шартнамәләре буенча торак урыннарын бирү нормасы буенча торак урыннары алу өчен базар бәясенең исәпләнгән күрсәткече (алга таба - исәп-хисап күрсәткече) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

СЖ = НП х РС х РЦ,

монда:

СЖ - социаль наем шартнамәсе буенча торак урын бирү нормасы буенча торак урын сатып алуның базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече;

НП - әлеге муниципаль берәмлектә гаиләнең бер әгъзасына торак урын бирү нормасы;

РС - гаилә әгъзалары саны;

РЦ - әлеге муниципаль берәмлекнең уртача шартларына һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин ителешкә туры килә торган торак урын мәйданының бер квадрат метрының Татарстан Республикасында торак урын сатып алуга кире кайтарылмый торган субсидияләр исәпләү өчен тиешле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән гомуми мәйданның бер квадрат метрының уртача базар бәясеннән артмый торган уртача исәпләнгән базар бәясе.

а) ялгыз яшәүче граждан өчен:

СЖ = 71336 х 18 = 1284048,00 сум

б) ике кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 71336 х18 х 2 = 2568096,00 сум

в) өч кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 71336 х 18 х 3 = 3852144,00 сум

г) дүрт кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 71336 х 18 х 4 = 5136192,00 сум

д) биш кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 71336 х 18 х 5 = 6420240,00 сум

е) алты кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 71336 х 18 х 6 = 7704288,00 сум

ж) җиде кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 71336 х 18 х 7 = 8988336,00 сум

З) сигез кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 71336 х 18 х 8 = 10272384,00 сум

и) тугыз кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 71336 х 18 х 9 = 11556432,00 сум

к) ун кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 71336 х 18 х 10 = 12840480,00 сум

2. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләме СЖ исәпләү күрсәткеченә тигез итеп кабул ителә.

Граждан гаиләсенең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем күләменең максималь күрсәткече билгеләнә:

1) торак урын сатып алуга ипотека кредиты алу мөмкинлеге булган шәһәрләрдә - гаиләнең һәр әгъзасына туры килгән, түбәндәге формула буенча билгеләнә торган СЖ исәпләү хакы буенча торак урын сатып алу өчен агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле уртача айлык җыелма керем дәрәҗәсеннән чыгып:

**ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1 - (1 + ПС) $^{-КП}$ ) / (0,3 х РС),**

монда

ПД - гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган һәм СЖ исәп-хисап бәясе буенча торак урыны алу өчен агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле уртача айлык җыелма керемнең максималь күләме;

СЖ - исәп-хисап күрсәткече;

ПС - кредит буенча айлык процент ставкасы (унарлы вакланма), елга 7 %, ягъни айга 7/100/12 = айга 0,0058) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру буенча алдагы чаралар хакында» 2007 елның 02 августындагы 366 номерлы карары нигезендә)

КП - бөтен кредит срогына кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (айлар саны);

РС - гаилә әгъзаларының саны;

0,7 - кредит суммасы һәм фатир бәясе нисбәте;

0,25 - кредит буенча түләүнең гаилә айлык җыелма кереме белән чагыштырмасы.

"2025 елның 1 яртыеллыгындагы торак базарына анализ" 2025 елның 22 гыйнварындагы 19 номерлы "Татарстан Республикасы Бәяләүчеләр берлеге" НПнең хаты нигезендә, Биектау муниципаль районында 1 квадрат метр торакның уртача бәясе 71336 сум тәшкил итә.

**Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең максималь кыйммәтенә исәп-хисап**

№1 табл.

| НП - торак урыны нормасы (кв. м) | СЖ - торак бинаны сатып алуның базар бәясе (СЖ = РС х РЦ х НП) (сум) | РС - гаилә әгъзалары саны (кеше) | РЦ - 1 кв. м торак бинаның базар бәясе (сум) | ПС - кредит буенча айлык процент ставкасы, % | КП - кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (ай) | Кредит суммасы һәм фатир бәясенең нисбәте | Кредит буенча түләүнең айлык җыелма керем белән нисбәте | ПД - керемнең максималь кыйммәте (сум) (гаиләгә) | Керемн е ң максималь кыйммәте (сум) (1 кешегә) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | |
| | 1284048 | | 71336 | 7/100/12 =0,0058 | 180 | 0,7 | 0,25 | | |
| 18 | 1284048 | 1 | 71336 | 0,0058 | 180 | 0,7 | 0,25 | 32236 | 32236 |
| 36 | 2568096 | 2 | 71336 | 0,0058 | 180 | 0,7 | 0,50 | 64471 | 32236 |
| 54 | 3852144 | 3 | 71336 | 0,0058 | 180 | 0,7 | 0,75 | 96707 | 32236 |
| 72 | 5136192 | 4 | 71336 | 0,0058 | 180 | 0,7 | 1,00 | 128942 | 32236 |
| 90 | 6420240 | 5 | 71336 | 0,0058 | 180 | 0,7 | 1,25 | 161178 | 32236 |
| 108 | 7704288 | 6 | 71336 | 0,0058 | 180 | 0,7 | 1,50 | 193413 | 32236 |
| 126 | 8988336 | 7 | 71336 | 0,0058 | 180 | 0,7 | 1,75 | 225649 | 32236 |
| 144 | 10272384 | 8 | 71336 | 0,0058 | 180 | 0,7 | 2,00 | 257884 | 32236 |
| 162 | 11556432 | 9 | 71336 | 0,0058 | 180 | 0,7 | 2,7 | 290120 | 32236 |
| 180 | 12840480 | 10 | 71336 | 0,0058 | 180 | 0,7 | 3,0 | 322355 | 32236 |